КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 сентябрь г.Казань № 852

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 407 нче; 2016 ел, 19 август, 572 нче; 2016 ел, 27 октябрь, 789 нчы; 2018 ел, 31 июль, 621 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1142 нче; 2019 ел, 18 март, 188 нче; 2020 ел, 2 март, 158 нче; 2020 ел, 13 май, 382 нче; 2020 ел, 7 август, 665 нче; 2021 ел, 2 март, 114 нче; 2021 ел, 28 июнь, 503 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Агентлык түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән – сәламәтлек саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән – Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән – мәдәният өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм файдалану), төрле диннәрнең дини берләшмәләре арасында

үзара аңлашуны һәм сабырлыкны ныгытуга ярдәм күрсәтү функциясен гамәлгә ашырганда (04.03*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән – фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.12*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлек белән идарә итү (01.03*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының Россия Федерациясе субъектларындагы башкарма хакимият органнары белән социаль-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү (03.07*);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән – авыл хуҗалыгы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

шәһәр төзелеше белән идарә итү (01.05*);

торак-коммуналь комплекс өлкәсендә торак фонды белән идарә итү (04.01.01*);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән – транспорт һәм юл комплекслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт белән идарә итү (01.13*);

социаль яклау белән идарә итү (04.06*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән – дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

элемтә белән идарә итү (03.04*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән – табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән – юстиция өлкәсендә

идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән – архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән – Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру функциясен гамәлгә ашырганда (03.05.04*);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән – бәяләрне (тарифларны) җайга салу белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.08*);

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты белән – туризм өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.09*);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән – матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.10*).»;

4.1 пунктта:

4.1.15 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.15. Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен, сатулар үткәрмичә, арендага бирү өчен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның, масштаблы инвестиция проектының Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтада билгеләнгән критерийларга туры килүен нигезли торган документларны кабул итүне һәм карап тикшерүне гамәлгә ашыра.»;

4.1.16 пунктчада «үтенечнамәләрне» сүзен «мөрәҗәгатьләрне» сүзенә алмаштырырга;

4.1.16$^1$ пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.16$^1$. Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның яки масштаблы инвестиция проектының Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтада билгеләнгән критерийларга туры килүе турында мотивлаштырылган бәяләмәләр проектларын, шулай ук социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объект яки масштаблы инвестиция проекты параметрларына үзгәрешләр кертүнең максатка ярашлылыгы турында мотивлаштырылган бәяләмәләр проектларын әзерләүне гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.16$^2$ пунктча өстәргә:

«4.1.16$^2$. Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектны урнаштыруны яки масштаблы инвестиция проектын тормышка ашыруны күздә тота торган килешүләргә үзгәрешләр кертү турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм мондый үзгәрешләр кертү кирәклеген нигезли торган документларны кабул итүне һәм карап тикшерүне гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.16$^3$ пунктча өстәргә:

«4.1.16$^3$. Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектны урнаштыруны яки масштаблы инвестиция проектын тормышка ашыруны күздә тота торган килешүләр төзүне, шулай ук мондый килешүләр реестрын алып баруны һәм аларны мониторинглауны гамәлгә ашыра.»;

4.1.17 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.17. Юридик затларның социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектны урнаштыру яки масштаблы инвестиция проектын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, арендага бирү турында, шулай ук социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объект яки масштаблы инвестиция проекты параметрларына үзгәрешләр кертү турында мәгълүмат бирелгән мөрәҗәгатьләренең җыелма реестрын алып бара.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин